УДК 821.512.145

***Н.М. Юсупова***

# КӘШШАФ ПАТИИ: ШАГЫЙРЬ, УКЫТУЧЫ, МУЛЛА

Статья посвящена изучению жизненного пути татарского поэта начала XX века Кашшафа Патии, имя которого до сих пор осталось в тени. В ходе исследования дается экскурс творчеству поэта, на примере отдельных его произведений выявляются основные тенденции развития его поэзии. Кашшаф Патии, жизненный путь и творчество которого является объектом нашего исследования, стоял в передовых рядах татарской просветительской мысли начала XX века.

Решая задачу воссоздания целостной картины развития национальной поэзии, татарское литературоведение обращается к малоизученным поэтическим наследиям. Изучение жизненного и творческого пути неизвестных до сих пор широкому кругу читателей или преданных забвению поэтов, возвращение в научный оборот тех или иных творческих личностей позволяет воссоздать, реконструировать литературный процесс, выявить национальные особенности татарской поэзии начала XX века. Этим объясняется актуальность нашего исследования.

Целью данной статьи является реконструкция жизненного и творческого пути Кашшафа Патии и введение в научный оборот отдельных, до сих пор неизученных поэтических произведений поэта.

Научная новизна статьи определяется тем, что в ней жизненный путь Кашшафа Патии впервые становится объектом системного изучения. Кроме того отдельные стихотворения поэта анализируются в рамках просветительской парадигмы с применением структурно-семиотического подхода.

**Ключевые слова:** татарская поэзия начала XX века, поэт, Кашшаф Патии, жизненный путь, друг Тукая.

The article is devoted to the study of the life path of the Tatar poet of the early twentieth century Kashshaf Patiya, whose name has remained in the shadows to this day. The study provides an overview of the poet's work, using the example of his individual works to identify the main trends in the development of his poetry. Kashshaf Patiya, whose life and work are the objects of our research, stood in the forefront of Tatar enlightenment thought at the beginning of the twentieth century. Solving the problem of recreating a holistic picture of the development of national poetry, Tatar literary criticism turns to little-studied poetic heritage. The study of the life and creative path of hitherto unknown to a wide range of readers or forgotten poets, the return to scientific circulation of certain creative personalities allows us to recreate, reconstruct the literary process and identify the national characteristics of Tatar poetry of the early twentieth century. This explains the relevance of our research. The purpose of this article is to reconstruct the life and creative path of Kashshaf Patiya and to introduce into scientific circulation some of the poet's hitherto unexplored poetic works. The scientific novelty of the article is determined by the fact that Kashshaf Patiya's life path becomes the object of systematic study for the first time. In addition, individual poems of the poet are analyzed within the framework of the educational paradigm using a structural and semiotic approach.

**Keywords:** tatar poetry of the early twentieth century, poet, Kashshaf Patiya, life path, friend of Tukai.

XX йөз башы татар шигърияте фикерләү киңлеге, фәлсәфи тирәнлеге белән дә, яңа агым һәм алымнарны әдәби мәйданда чарлавы белән дә сүз сәнгате тарихында аерым чорны тәшкил итә. Бу яңарышны иҗаты белән үз сүзен әйтеп, милли әдәбият үсешенә саллы өлешен керткән әдипләр янәшәсендә татар әдәбиятына борылыш алып килү нияте белән янган, аны дөнья әдәбиятлары югарылыгына чыгару омтылышы белән яшәгән яшь авторлар әйдәп бара. Р. Гайнанов төзегән исемлеккә нигезләнеп, аларның 300 дән артып китүен дә исәпкә алсак [14: 4], XX йөз башында татар шигъриятенең куәтле бер көч булуы аңлашыла. Шуңа да XX йөз башы әдәбият тарихында күпсанлы сүз осталарының төрле яклап колачлы эзләнүләр алып бару дәвере буларак бәяләнә дә. Кызганычка каршы, күбесенең иҗади мирасы, гарәп графикасындагы кульязмалары, бүген дә үз тикшеренүчесен көтеп, киштәләрдә кала бирә. Мондый каләм ияләре арасында Тукай шигъри мәктәбе вәкиле Кәшшаф Патии исеме дә бар.

Габделкәшшаф Мөхәммәтшәриф улы Патиев (Кәшшаф Патии исемен ул үзенә әдәби псевдоним итеп ала) – шагыйрь, укытучы, мулла – 1884 елның 29 декабрендә Саратов губернасы Зимничә авылында (хәзерге Ульяновск өлкәсе) мулла Мөхәммәтшәриф белән Хәлифә гаиләсендә дөньяга килә [9: 142]. Гаиләдә бердәнбер ир бала була, шуңа әтисе белән әнисенең игътибар үзәгендә үсә, Кәшшафның кечкенәдән думбра, мандолина кебек уен коралларында өйрәнүе бу гаиләнең үз чоры өчен шактый алдынгы карашлы булуы турында сөйли.

Башлангыч белемне үзенең әтисеннән алган Кәшшаф 1905 елда Казанга килә [1] һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Уку йортында 9 ел – 1905 елдан 1914 елга кадәр белем ала, 1915 елга кадәр Казанда яшәве мәгълүм. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку дәверендә булачак шагыйрьнең Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге әдәби түгәрәк эшендә катнашуы турында билгеле.

Мәдрәсәдә укыганда ук, төгәлрәге 1907 елда, Кәшшаф туган авылында мулла вазифасын да башкара. З. Рәмиев фикеренчә, ул Зимничәдә 1909 елда мулла була [14: 197]. Әмма Кәшшафның муллалык эшенә нәкъ менә 1907 елда керешүе Зимничә авылының 1 нче мәчете метрика китабындагы (1912 ел өчен) белешмә белән раслана. Шагыйрьнең әтисе – Мөхәммәтшәриф Патиев – беренче имам, 28 яшьлек Габделкәшшаф икенче имам буларак теркәлгән. Шунда ук без Кәшшафның имам вазифасына керешеп китү датасын да күрә алабыз: «Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә» укучы Габделкәшшафның имам вазифасына 1907 елның 10 маеннан № 5398 номерлы указ нигезендә раслануы турында белешмә беркетелгән [9: 144]. 1908 елда 23 яшьлек Кәшшаф Саратов губернасының Иске Мәстәк авылында китапханә ачу эшләрендә дә башлап йөри, аның исеме китапханәне гамәлгә куючылар исемлегенә теркәлгән [13: 148].

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку чорында типографияләрдә эшләгән һәм Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге әдәби түгәрәккә йөргән Кәшшаф Г. Тукай даирәсенә килеп керә. Бер үк вакытта медицина

белән кызыксынып китә, хәтта ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан император университетының медицина факультетына лекцияләргә йөри. Тукай даирәсендәгеләрнең аны шагыйрьнең «сәламәтлек буенча урынбасары» дип тә йөртүе билгеле. Шагыйрьнең кызы Роза этисенең Тукай үлгәнче аның янәшәсендә булуы турында сөйли.

Кәшшафның яңа фикерле яшьләр даирәсенә килеп эләгүе мәдрәсә укытучылары арасында «борчу тудыра» һәм алар егетнең этисенә хат юллый. Мулла, улының кире туган авылына әйләнеп кайтуын таләп итеп, хатлар яза. Кәшшаф берничә ел этисенең теләгенә каршы килеп, шигырь язып, типографияләрдә эшләп, шулардан килгән акчага яшәргә омтылып карый, әмма ахырда, этисе матди яктан бөтенләй ярдәм итми башлагач, 1915 елда туган ягына кайтып китәргә мәҗбүр була. Туган авылы Зимничәдә мәктәп ачып җибәрә һәм балалар укыту белән шөгыльләнә башлый [16: 267].

Гаилә тарихына килсәк, 1909 елда Кәшшаф Сәхибҗамал (1888–1939) исемле кызга өйләнә, беренче никахыннан 5 балалары туа: Нургали, Тәүфикъ, Гобәйдә, Маһирә, Надирә.

Новосибирск шәһәренә командировкага баргач, Кәшшаф Зәйнәп (1901–1966) исемле үзеннән шактый яшь ятимә кыз белән таныша, аңа өйләнергә карар кыла. Зәйнәп, Кәшшафның өйләнгән кеше икәнлеген дә белмичә, икенче хатын сыйфатында Зимничә авылына кайта, бер-бер артлы өч бала таба. Бер гаиләдә ике хатын мөмкин булган кадәр тынычлыкны саклап, яхшы мөгамәләдә яшәргә тырышалар. Балалар да дус-тату булып, аралашып яшиләр һәм туганлык җепләрен саклыйлар. Шушы елларда Кәшшаф Зимничә авылында яңача укытуга корылган мәктәп ачу артыннан йөри, хәтта Хвалыннан яңа карашлы укытучыларны эшкә чакыра. Шушы гамәлләре өчен үз авылында эзәрлекләүләргә дә дучар була, әмма башлаган эшен ахырына җиткерә: мәктәпне ачып, эшләтеп җибәрүгә ирешә [9: 149].

1920–1921 елгы ачлык чорында, наданлыкны бетерү шаукымына ияреп, берничә укытучы гаиләсе Үзбәкстанның Хива шәһәренә китәргә карар кыла, алар арасында Кәшшаф белән Зәйнәп тә була. Чит җирләрдә бик авыр шартларда эшләргә туры килә, шушы елларда активлашып киткән басмачылар хәрәкәте аеруча кыенлыклар тудыра, шулай да алар үз юлларыннан тайпылмыйлар, Хива шәһәрендә 1927 елга кадәр эшләп, кабат туган якларына әйләнеп кайталар.

Әмма тынычлап яшәргә насыйп булмый, 1929 ел Патиевлар гаиләсенә зур кайгы алып килә: мулла гаиләсе буларак, өлкән яшьтәгеләр белән бергә аларны да Архангельск шәһәренә сөрәләр. Гаилә архивында Патиевлар гаиләсен сөрүгә бәйле 1929 елның 28 ноябре белән имзаланган архив документының күчермәсе саклана [9: 151]. Әлеге документта мулла гаиләсенең «Совет властена каршы эш алып баруда» гаепләнүе күрсәтелә [9: 150]. Юлда барганда, укытучылык эше белән шөгыльләнүен, прогрессив, инкыйлаби шигырьләр язуын истә тотып, Кәшшафны азат итәләр. Зәйнәп белән никахтан туган ике

кызлары юлдагы авырлыклардан үлеп кала, Зәйнәп үзе, гаепләнүчеләр исемлегендә булмавын белеп алып, улы Иркин белән Новосибирск шәһәренә туганнары янына качып китә. Сәхибҗамал исә балалары белән Архангельск шәһәренә барып төпләнә, кызганыч ки, Кәшшаф бу гаиләсе белән авырлыкларны бүлешми. Сәхибҗамалга балаларны ялгызы үстерергә, яңа җирдә аякка басырга туры килә. 1939 елда хатын каты авырып вафат була, озак еллар сәяси репрессия корбаннары исемлегендә йөри һәм 1996 елда гына реабилитацияләнә.

Кәшшаф Новосибирск шәһәреннән Зәйнәпне эзләп таба, һәм гаилә Үзбәкстанга күчеп китә. Шушы китүдән алар биредә төпләнә: 1933–1955 елларда Ташкент, соңрак Әндиҗан, Каракалпак-Найман шәһәрләрендә яшиләр, укытучылык эшчәнлеген дәвам итәләр [16: 292]. Кәшшаф һәм Зәйнәпнең җәмгысе 11 балалары туып, күбесе, ачлык елларын кичерә алмый вафат була, бары Иркин (1926–2001), Роза (1935–2017), Илтөзәр (1937–1996) генә гомерле булып чыга. Кәшшафка Үзбәкстанда да шактый кыенлыклар кичерергә туры килә: шәхес культы, сугыш һәм сугыштан соңгы авыр еллар бу гаиләгә дә кагыла. Беренче гаиләсендә калган улы Нургали сугышта һәлак була, Иркин, күп яралар алып булса да, исән-сау әйләнеп кайта.

Сугыштан соңгы елларда Кәшшафка колхозда агроном, бригадир вазифаларын да башкарырга туры килә, виноград үстерү, умартачылык белән шөгыльләнә, берара Зур Фирганә каналы төзелешендә катнашуы, агитация эше белән шөгыльләнүе дә билгеле.

1955 елда, яңа йорт төзеп, гаилә Куйган Ярга күченә, әмма бәхет озакка бармый. 1966 елда Зәйнәп дөнья куя, 1971 елның 13 февралендә 87 яшендә Кәшшаф та бакыйлыкка күчә.

Шагыйрь буларак Кәшшаф Патии исеме 1907 елдан күренә башлый: «Әлгасрелҗәдид» журналының 25 гыйнвар санында аның беренче шигыре басылып чыга. Шуннан башлап, төрле исемнәр астында, «Кашшаф Патин, К. Патин, К. Патии тәхәллүсләре» [10: 144] белән шагыйрьнең шигырьләре дөнья күрә. Хәйрулла Йосфи наширлегендә эшләнгән һәм 18 шигырьне берләштергән беренче шигырьләр китабы 1910 елда «Кәшшаф Патии шигырьләре» исеме белән Кәримовлар матбагасында басылып чыга [3]. 1915 елда аның 30 лап шигырен туплаган «Әшгарь» исемле икенче шигырьләр җыентыгы татар укучысына килеп ирешә [4]. Моннан тыш текстологлар тарафыннан Габделкәшшаф Зимничәви авторлыгында 1906 һәм 1912 елларда басылган «Тугыз чәчәк» җыентыгы да Патиига нисбәтле дип карала [12: 519; 14: 197].

Кәшшаф Патииның беренче чор әсәрләре мәгърифәтчелек идеалларына йөз тотып языла, күп шигырьләрдә мәгърифәтчелеккә хас дөнья сурәте тудыру көчле, чөнки мәгърифәтчелек карашлары шагыйрь мәйданга чыккан 1907 елларда әле татар җәмгыяте өчен гаҗәп актуаль була. Мәгърифәтчелек агымы кысаларында язылган шигырьләрендә аң-белем, тәрбия, кадимчелек проблемалары күтәрелә, татарның алгарышы мәгърифәтчелек идеаллары белән бәйләп аңлатыла. Мондый шигырьләрдә лирик герой татар халкын алга җибәрү,

җәмгыятьне яңарту, кешеләр яшәешен камилләштерү максатына йөз тота. Шигырьләрдә күтәрелгән мотивлар да мәгърифәтчелек кысаларында яңгырый: татар җәмгыятенең аң-белем дәрәҗәсен үстерү («Ерак мәмләкәттәге дустыма», «Дустыма», «Мөхәммәдиядән: Сөальләр», «Каләмгә», «Сукачыга», «Яңа тормышка»), татар җәмгыятен рухи яңарышка өндәү («Гыйбрәт», «Гаҗиз милләткә»), хатын-кыз азатлыгы («Чапан»), кадимчелек («Ватсаң») мотивлары шундыйлардан.

Мисалга шагыйрьнең «Каләмгә!» шигырен алыйк. Әсәрдә риторик эндәш алымы ярдәмендә лирик герой каләмгә мөрәҗәгать итә, аны «сызарга, язарга, гаҗәп серне сөйләргә» өнди. Шигырьдәге төп оппозиция традицион эчтәлекле: искелек / яңалык (кадимчелек / җәдитчелек). Шагыйрь аларның татар кешесен, татар дөньясын рухи үзгәрешкә яки торгынлыкка илтерлек ике юл булуын күрсәтә:

Гыйбадәт урынына шалтырдаталар
Күк төймәләрне,
Мөкатдәс кануныңны боргалыйлар
Арлы да бирле.
Яна йөрәк, яна, түзми,
Сүнәрме әй бетәр тизме?
Югыйсә алдыйлар хәзер
Кадыйлар йөзтүбән йөзне [3: 16].

Лирик герой тарафыннан дини үзгәрешләр кирәклеге ассызыклана, нәкъ менә шул үзгәрешләр яңарышның иң беренче һәм мөһим нигезе итеп куела, татар җәмәгатьчелегендәге үзгәрешләрнең дини үзгәрешләрдән башланырга тиешлеге раслана. Шагыйрь каләмне, әдәби иҗатны шушы үзгәрешләрне әйдәп барырлык, мондый олы бурычны үз өстенә алырлык көч сыйфатында күрә, шул рәвешле шигъри сүзнең, әдәбиятның ролен югары күтәрә.

Кәшшаф Патии иҗатында аерым бер бәйләмне сатирик әсәрләр тәшкил итеп, алар тәнкыйть мотивы тирәсенә туплана. Лирик геройның тәнкыйте надан муллаларга, иске карашлы татар җәмгыятенә, әхлаксызлыкка, дини фанатизмга, икейөзлелеккә каршы юнәлтелә. Мисал өчен, «Мөхәммәдиядән» шигырендә татар җәмгыятендәге катлаулар ачы көлү объекты булып яңгырый:

Бере – ишан, гаҗәп хөрмәт вә сыйда,
Павыска тулыдыр каз, коркасы да.

Бере – мөрид, өмет итәр ишандан,
Бер өч пуз казга насыйб иршадындан.

Бере – суфи, кавын төшен да ярмый,
Кеше күргәндә һич гөнаһка бармый.

Бере – шәкерт, егерме ел укыйдыр,
Түбән карый, күтәрми баш, суфидыр.

Бере мәдрәсәдә, хәлфә исемле,
Утыз биш-кырык сәнә гомер кичендә.

Бере – мулла, утыра түр башында,
Егерме ел нәтиҗәсе дә шунда.

Бере – фәкыйрь, ач үләргә теләми,
Эш эшләми, бай абзыйдан теләге.

Бере – байбәтчә, туймыйдыр ләззәттән,
Өчәр хатын аладыр ул симездән [3: 5].

Әлеге шигырьдә мулла-ишаннарның һәм шәкертләрнең жыелма образлары тудырыла, Кәшшаф Патии татар динчеләреннән, шәкертләрдән, бай-сәүдәгәрләрдән, аларның яшәү рәвешеннән ачы көлә, татар дөньясындагы төрле катлау ияләренең дөньяга карашын, ваемсызлыгын, бер көн белән яшәү омтылышын тәнкыйтьли. Шигырь каләм һәм әдәбиятның татар яшәешен төбеннән-тамырыннан үзгәртергә тиешлеген раслау белән тәмамлана.

Шагыйрь иҗатындагы өченче төркем шигырьләр мәгърифәтчелек романтизмы кысаларында иҗат ителә, мондый шигырьләрдә лирик герой милли музыкага, милли яшәешкә гашыйк кеше буларак кабул ителә. Алар, нигездә, ялгызлык халәтендәге, бу дөньяда бәхет таба алмый читләшкән лирик геройның кичерешләре хакында бәян итә. Мәсәлән, «Мандалин» шигырен алыйк. Дөньяда яшәү ямен югалткан, кайгылы, эче пошкан, күңеле таш булып каткан лирик герой шигырьнең буеннан-буена мандолинга мөрәҗәгать итә, аннан татар дөньясын дәрт-моңга, ләззәткә күмүен, үлгән күңелләрне уятуын үтенә. Һәр тезмәдә капма-каршы куелган сурәтләр аркылы рухсызлык һәм милли моң мәсьәләсе күтәрелә. Шигырь кысаларында музыканы, сәнгатьне югары күтәрү, аның көчен өстен итеп күрсәтү ачык күренә, үсештән туктаган, үлгән милләтне татар музыкасы, сәнгать, татар җыры уята, кузгата, алга җибәрә ала, дигән фикер төп идея булып яңгырый:

Милли дим, тәэсирләнәм, күз
карасын яшьләткәлим.
Милли-милли әйттерәм мин,
Там-тарим, там, там-тарим.

Таш күңелне шундый пакь
тавыш белән йомшарткалыйм.
Яртылап сүнгән рухымны
Тергезәм, нурлаткалыйм [4: 10].

Шул рәвешле, Кәшшаф Патии шактый катлаулы һәм каршылыклы гомер юлы үтә, татар шигъриятен үстерүгә үзенең өлешен кертә. Әмма 1915 елдан соң ул актив иҗат эшчәнлегеннән читләшә, 1917 елгы вакыйгалардан соң, мулла буларак, авырлыклар алдында кала, гел күченеп йөрергә мәҗбүр була. Үзбәкстанга күченгәннән соң, үзе өчен генә язса да, шигырьләрен газета-журналларда бастырмый.

XX йөз башында иҗат эше белән шөгыльләнеп тә, игътибардан читтә торган Г. Харис, Д. Гобәйди, Ф. Ибраһимов, Б. Мирзанов, Ф. Агиев, З. Бәшири һ. б. кебек йөзләгән татар шагыйрьләре кебек,

Кәшшаф Патии иҗаты да, тормыш юлы да моңа кадәр күләгәдә кала килде. Ләкин аларның иҗади мирасын бөтенлекле күзалламый торып, бу чор татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юлларын тулысынча ачу мөмкин түгел.

**Әдәбият**


1. *Әскәров М.* Патиевлар // Ватаным Татарстан. 2000. 11 август.
2. *Патии К.* Әлгасрелҗәдид журналына // Әлгасрелҗәдид. 1907. 25 гыйнв.
3. *Патии К.* Кәшшаф Патии шигырьләре. Казан: Электро-тип. «Урнэк», 1910. 16 б.
4. *Патии К.* Әшгарь. Казан: Кәримовлар матбагасы, 1915. 31 б.
5. *Патии К.* Тормыш // Идел. 1910. № 252.
6. *Патии К.* Музыка // Идел. 1910. № 238.
7. Патии К. Билгеле // Шура. 1914. № 14.
8. Патии К. Тукайга // Сабыйлар догасы. Казан, 1915. Б. 4.
9. Род Патиевых / Шәхси архив. 240 с.
10. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. 10 нчы чыг. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр / төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.Н. Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. 300 б.
11. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 4 т.: XX йөз башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 533 б.
12. Татар поэзиясе антологиясе: 2 томда. 1т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 544 б.
13. Татары Саратовского Поволжья: энциклопедический справочник / ред. совет: Ф.А. Рашитов (председатель) [и др.]. Саратов: КУБиК, 2020. 252 с.
14. Татар шигърияте: XX йөз башы / төз. З.З. Рәмиев. Казан: Мәгариф, 2004. 447 б.
15. *Юсупова Н.М.* Забытые имена: Кашшаф Патии // Филология и культура. Philology and Cultura. 2024. № 2 (76). С. 266–271.
16. *Юсупова Н.М.* Кәшшаф Патии: тормыш юлы һәм иҗаты // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы IV Междунар. науч.-практ. семинара, посвящ. 85-летию Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова (9–10 октября 2024 г., Казань) / сост. Л.И. Фахрутдинова. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 291–296.
17. Яңа әсәр // Идел. 1910. № 241.


*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024*

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы профессоры*

***Юсупова Нурфия Марсовна,***
*доктор филологических наук, профессор кафедры татарской литературы Института Филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета*

*faikovich@mail.ru*